# Без яши торган тиралекнең экологик проблемалары

# Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы
# Качкын төп гомуми белем бирү мәктәбе




***Төзеде:***

**7 сыйныф укучысы**

***Шарапова Айгизә***

***Җитәкчесе:***

***биология укытучысы***

***ГибадуллинаР.Н.***

***2017 ел***



- **Проектның актуальлеге** :

1. Авыл тирәсе пычрану; 2. Чишмәләрнең кимүе;

3. Кеше эшчәнлеге аркасында урамнарның пычрануы;

4. Чүпнең тиешле урынга гына тапшырылмавы;

5. Экологик проблема барлыкка килү .

**Максаты һә м бурычлары** :

1.Авылны яшелләндерү ; 2. Табигатькә сакчыл караш барлыкка китерү ; 3. Чишмәләрне чистарту , саклау ; 4. Кешенең сәламәтлеге турында кайгырту ; 5. Чүпне тиешле урынга гына җыюны оештыру ; 6. Туган якка мәхәббәт, патриотизм рухы тәрбияләү ; 7. Үз - үзеңә хезмәт күрсәтү культурасын үстерү ;

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

1.Авылны һәм аның тирә-ягын чүптән арындыру;

2. Сулыкларның чисталыгын тәэмин итү;

3. Кешеләрнең гомер озынлыгын арттыру;

4. Кешеләрне рухи яктан баету

5. Һава чисталыгын саклау;

Безнең якның табигате бай, күптөрле.
Аны ярату өчен - аңларга,
аңлау өчен аның белән якыннан
танышырга кирәк.



Качкынымның болын, таллыклары
Алар минем йөрәк сагышым.
Катлы таудан аккан саф чишмәсе
Ул бит минем гомер агышым.
Әй,Качкыным,туган авылкаем,
Әйт син миңа был-был тавышы
Нигә синнән аерылгач кына
Моңсулана сулар агышы.
.



**Элегрәк кешелек дөньясы үзенең сәнәгать эшчәнлегендә су, һава, туфрак, файдалы казылмалар кебек табигый байлыклар иксез-чиксез күп һәм бушлай дигән фикердән чыгып эш йөрткән. Мохитнең үз-үзен сафландыру механизмы эшләсен өчен, җитештерү калдыкларын яхшылап тарату җитә, дип санаган. Сәнәгать предприятиеләре калдыкларын сулыкларга агызу, газ-тузан катыш кебек зарарлы матдәләрне атмосферага чыгару һ.б. нәкъ менә шуның белән аңлатыла да. Әмма болай фикер йөртү һич тә дөреслеккә туры килми. Табигый байлыкларның да чиге бар, ә мохитне берөзлексез пычратып тору экологик халәтнең бозылуына, табигатьнең зарарлануына китерә. Кеше үз эшчәнлеге белән үк Җир йөзендәге бар тереклекне, шул исәптән үзен дә юкка чыгарырга мөмкин!**





## Экологик проблемалар

**Экологик проблемалар – ул кешенең яшәү шартлары начарлану проблемалары, алар кешенең табигать белән үзара тәэсир итешүе нәтиҗәсендә килеп чыга, һәм кешенең сәламәтлегенә, тормышына, хәтта кешелек җәмгыяте өчен дә куркыныч яный.**

*Киләчәктә ни булыр???*

**Экологик проблемалар дөнья масштабында гына түгел, ә үзебез яшәгән тирәлектә дә каралырга тиеш. Кешеләр табигатьне пычраталармы? Бу хәлдән чыгу юллары бармы?**











Кешелек алдында калдыкны кая куярга дигән проблема килеп басты. Безгә әллә нинди глобаль проблемалар турында сөйләгәнче эчкән су шешәләрен, ашаган ризык чүпләрен теләсә кая атмаска, җыеп барырга һәм аларга икенчел куллану табарга өйрәнергә кирәк. Ишек алдында, урамда сыра, су савытлары, кәгазьләр, консерв банкалары аунап ята. Кая карама чүп өеме. Ә бит табигатьне саклау шул кечкенә нәрсәдән - үз артыңнан җыюдан башлана. Кечкенәдән үк тәртипсезлеккә өйрәнеп үскән бала үскәч табигатькә сак карар дип кем әйтә ала? Безне борчыган бу сорауларга җавап эзләп иң беренче чиратта гаиләдә барлыкка килгән кайбер көнкүреш калдыкларының таркалу вакыты белән таныштырып китәм:



- Кәгазь 2 ел.
- Пыяла 1000 ел
- Консерв банкасы 30 ел
- Полиэтилен 2000 ел




Авылның төзеклеге, чисталыгы безнең һәрберебезгә бәйле. Авыл буенча күз ташласак, җитди кимчелекләр бар. Бажана буйларында ерымнар ясалып, ярлар ишелеп килә. Бу ерымнарга кешеләр төрле чүп-чар ташлыйлар. Яңгыр-кар сулары белән бу пычрак матдәләр елгага агып төшәләр. Калган чүп-чар таралып ята. Көнкүреш калдыкларын, чүп-чарларны махсус билгеләнгән урыннарга түгелсә, ерымнарны күмдереп, анда агачлар утырту эшләре дә башланса, әйбәт нәтиҗә бирер иде. Елга буйларына чүп-чар түкмәскә, табигый һәйкәлләрне сакларга кирәклеге турында инде ничә еллар буена аңлату эшләре алып барылуга да карамастан, хәл һаман да уңай якка үзгәрми. Авылларда яшәүче һәр кеше елга, чишмә, күл буйларының чисталыгын сакларга тиеш.





# Алга киткән илләрдә бер елда бер кешедән калган калдыклар




# Тормыш шулай дәвам итсә, бездән соң килгән буынга нәрсә калыр?








Авылда кайбер йорт яннарын чиста тотмыйлар. Элек кенә йорттан чыккан бөтен ташландыкны бер урынга җыйганнар да, ат арбасына төяп авыл читенә ташыганнар. Хәзер исә чүп-чарларны капчыкларга тутырып куйсак ,чүп җыю машинасы алып китә.Ә юынтык су чиләге күтәргән апалар ерак йөрми: "йөк"не юл уртасына гына каплыйлар. Мондый чүп-чардан арыну өчен санитария ике айлыгы гына түгел, яртыеллык та ярдәм итмәячәк. Кем гаепле, дигән сорау биреп тору артык. Дөрес, бик матур йорт-җирләр дә бар. Аларга "Үрнәк тәртипле йорт" дигән такталар эләргә кирәк. Сабан туе алдыннан урамнар арасында чисталык һәм яшелләндерү буенча ярыш игълан ителсен, Сабан туенда иң чиста, иң төзек урамга котлап бүләк бирелсен иде. Урамнарда агачлар утырту эшен дә җанландырып җибәрәсе бар. Яшеллеккә, чисталыкка зур игътибар бирелсен иде.





Әйләнә-тирә мохитне саклау һәммәбезнең дә уртак бурычы. Табигатькә зыян китерүчеләргә, иртәме-соңмы, кылган гамәлләре өчен закон алдында җавап бирергә туры килсен иде. Табигатьне саклау без яшәгән йорттан, урамнан һәм авылдан башланганын онытмасак иде. Шулай итеп, дөньяның экологик проблемалары безнең һәрберебезгә кагыла. Рәхәтлек, хозурлык биргән табигатебезнең мәңгелек яшәешен тәэмин итү – безнең буынга төшкән җаваплы бурыч. Безнең яшәү урыныбыз чиста, төзек булырга тиеш.